Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-10**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районСоветының 2010 елның 15 октябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын алмаштыругаконкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмә хакында” гы I-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга тәңгәлләштерү максатларында,“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 маддәсенә, 2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы25-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенә,Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексының8, 19 маддәләренә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45-ЗРТ номерлы законының 26 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 48 маддәләренә туры китереп,Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районСоветы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районСоветының 2010 елның 15 октябрендәге “Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасыналмаштыруга конкурс үткәрү тәртибетурында Нигезләмә хакында” гы I-4номерлыкарарына (Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районСоветының 2013 елның 22 июлендәге XXVII-3 номерлы, 2014 елның 13 декабрендәге XLII-5 номерлы карарлары тарафыннан кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) преамбуладагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 46 маддәсенә, Татарстан Республикасының 2008 елның 17 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында”гы

5-ЗРТ номерлы законына таянып”дигән сүзләрне “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 48 маддәсенә, Татарстан РеспубликасыныңМуниципаль хезмәт турындагы кодексына” сүзләренә алмаштырырга;

1.2)Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын алмаштыруга конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәдә:

а) 8 пунктның 1 пунктчасындагы өченче-бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“б) югары профессиональ белемле;

в)икеелдан да ким булмаганмуниципаль хезмәт стажы яки белгечлеге, шул юнәлештәге әзерлеге белән дүрт елдан да ким булмаган хезмәт стажы булган;

г)идарә итү эшчәнлегендә биш елдан да ким булмаган тәҗрибәсе. Идарә итү эшчәнлеге дигәндә оешманың, дәүләт органының, муниципаль органның җитәкчесе, җитәкче урынбасары вазыйфаларында, шулай ук аларның структур подразделениеләре җитәкчеләре вазыйфаларында хезмәт кую аңлашыла;”;

б) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9. Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын алмаштыруга конкурс үткәрү турындагы һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында хәбәр “Авыл офыклары” (“Сельские горизонты”) район газетасында басыла, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтындаурнаштырыла.”;

в) 12пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12.конкурста катнашуга теләге булган затлар конкурс комиссиясенә түбәндәге документлар теркәлгән гариза тапшыралар:

1)башкарма хакимиятнең федераль органы вәкаләтлесе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм кул куелган анкета;

2)паспорт;

3)хезмәт кенәгәсе, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелү очракларыннан гайре;

4) белем турында документ;

5)мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы,хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелү очракларыннан гайре;

6)Россия Федерациясетерриториясендә тору урыны буенча салым органында физик затны учетка кую турындагы таныклык;

7) запаста исәпләнүче гражданнар өчен һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен – хәрби учет документлары;

8)муниципаль хезмәткә керүгә киртә булырдай авыруның булмавы хакында медицина оешмасының заключениесе;

9)үзенең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлары, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында Татарстан Республикасының 2017 елның 19 июлендәге

“ Муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасын алмаштыруга дәгъва итүче гражданнарның, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасын алмаштыручы затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре

хакында мәгълүматларны тапшыру тәртибе турында”гы 56-ЗРТ номерлы законда күздә тотылган мәгълүматлары”;

10)2007 елның 2 мартындагы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә каралган мәгълүматлар;

11)федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күздә тотылган башка документлар.

Конкурсант һөнәри әзерлеген сыйфатлаучы башка документлар да тапшырырга мөмкин.”;

г) 16 пунктта “30” көн дигән сүзләрне “30 календарь көн” сүзләренә алмаштырырга;

д) 24 пунктта “өч көнлек срокта” дигән сүзләрдән соң “,календарь көннәрдә исәпләнүче” сүзләре белән тулыландырырга;

е) 27 пунктта “өч көнлек срокта” дигән сүзләрдән соң “,календарь көннәрдә исәпләнүче” сүзләре белән тулыландырырга;

ж) 28 пунктта “ун көнлек срокта” дигән сүзләрдән соң “,календарь көннәрдә исәпләнүче” сүзләре белән тулыландырырга;

з)Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын алмаштыруга конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә кушымтаны (анкета формасын) көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов